ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.02.2026 Олы Кайбыч ав. № 127

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Хөкем ителгәннәргә мәҗбүри һәм төзәтү эшләре рәвешендәге җәзаларны үтәү урыннарын билгеләү турында»2025 елның 19 декабрендәге 571 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Җинаять-башкарма кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 23 июлендәге 219-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Хөкем ителгәннәргә мәҗбүри һәм төзәтү эшләре рәвешендәге җәзаларны үтәү урыннарын билгеләү турында»2025 елның 19 декабрендәге 571 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- исемендә һәм преамбуласында «һәм төзәтү» сүзләрен төшереп калдырырга;
- 2 пунктны төшереп калдырырга;
- 2 нче кушымтаны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында» бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Н. Макаров